Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№ 8 (8)

24 ноябрь 2011 ел

## • Ике авыз сүз

21 ноябрь көнне ректоратның чираттагы утырышы булды. Анда КФУның «Европа университетларында инженерлар әзерләүнең алдынгы тәҗрибәсе» дип аталган халыкара фәнни-гамәли семинарда (Чехия техник университеты) катнашуы һәм университетның Үсеш программасын тормышка ашыру турында хисап тыңланды. КФУның Телләр институты директоры Г.Баһаутдинова үз бүлекчәсенең Үсеш программасын тәкъдим итте.

Әүвәл инновацион эшчәнлек буенча проректор Н.Кашапов хисап тотты. Ул Чехия техник университетының укыту-лаборатория базасы, семинарда катнашучылар турында сөйләде. Н.Кашапов КФУ һәм ЧТУ арасында хезмәттәшлек турында килешү эшләнүен һәм безнең университетта да инженерлар әзерли башларга иде дигән тәкъдимен әйтте. Ректор И.Гафуров чит ил уку йортларының фән һәм мәгариф өлкәсендәге уңай тәҗрибәләрен өйрәнү кирәклеккә басым ясады, КФУ тәҗрибәле үрнәк булдыру белән шөгыльләнергә тиеш дигән фикерен җиткерде.

Телләр институты директоры Г.Баһаутдинова катнашучыларны институтның структурасы, бурычлары һәм максатлары белән таныштырды. Хәзерге вакытта чит телләрне өйрәнүнең актуаль булуы турында кабатлап әйтте. Ә КФУның Үсеш программасын реализацияләү турында икътисади һәм стратегик үсеш мәсьәләләре буенча проректор М.Сафиуллин сөйләде. Ул сатып алынган әйберләр турында хисап тотты һәм барлык структур бүлекчәләр тиз арада үзләренең Үсеш программасын тормышка ашыру буенча мәгълүмат әзерләргә тиеш, диде.

Фәнни эшчәнлек буенча проректор Д.Нургалиев университетның фән үсешенә тукталды, фәнни мәкаләләрне чит ил нәшриятларында да бастыруның мөһимлегенә басым ясады. И.Гафуров фәнара тикшеренүләр һәм фәнни эшләрнең университет үсешенә уңай йогынты ясавын билгеләп үтте.

Ректор узган Студентлар спорт фестивален дә игътибарсыз калдырмады. Ул бу бәйрәмне оештыру һәм үткәрүдә актив катнашканнарга һәм университетның туган көненә багышланган концертны әзерләүчеләргә рәхмәт белдерде. Утырыш уку-укыту буенча проректор Р.Минзариповның «Биоинформатика» дип аталган магистрлык программасы ачылу турындагы мәгълүматны җиткерүе белән тәмамланды.

• • • •

Кичә ректор И.Гафуров «Уникс»та Универсиада авылында яшәүче студентлар белән очрашты. Уку йортының эшчәнлеге белән таныштыргач, ул сорауларга җавап бирде. Идел буе төбәгенең әйдәп баручы белем учагында укыган студентларның 4 декабрь көнне узачак сайлауларда да актив катнашуына ышануын белдерде.

• • • •

21 ноябрь көнне университетта «Арктик экосистеманың экология өлкәсендә Россия-немец хезмәттәшлеге: нәтиҗәләр һәм перспективалар» дип аталган халыкара-фәнни семинар узды. Россия һәм Германиянең 20ләп фәнни оешмасыннан 50дән артык алдынгы галим җыелды. Семинарның төп максаты Арктиканың Россия өлешендә узган уртак тикшеренү нәтиҗәләре, мониторинг күзәтү үзәкләрен арттыру, хезмәттәшлекне тагын да ныгыту турында сөйләшү булды. Климатик модельләштерү өлкәсендә ирешелгән уңышлар, мәгълүматларны туплау һәм анализлау, актуаль фәнни хезмәтләрне барлау глобаль җылытуның көчәюе турында нәтиҗә чыгарырга ярдәм итте.

• • • •

Шул ук көнне КФУ белән Монклер дәүләт университеты (Нью-Джерси штаты, АКШ) арасындагы хезмәттәшлекне тормышка ашыру максатыннан, «Инглиз телендә белем бирү» программасының маркетинг буенча директоры, Монклер университеты профессоры Грегори Штракса килде. Ул уку йорты җитәкчелеге белән очрашты, университет тарихы музее, Филология һәм сәнгать институтының Америка «почмагы» белән танышты.

*ksu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Алия Галимуллина фотосы

# «Мәктәп»тә тагын тантана

**Динә МӨХТӘСИПОВА,**
хәбәрче

Кичә КФУның Мәгълүмати технологияләр һәм системалар (ИТИС) югары мәктәбендә тантаналы төстә «Fujitsu Lab GDC» лабораториясе ачылды. Әлеге лаборатория Татарстанда «Fujitsu» компаниясенең беренче укыту-җитештерү проекты булачак.

«Fujitsu» – мәгълүмати технологияләр базарында иң борынгы компанияләрнең берсе. Аңа 1936 елда Японияд нигез салына. Ләкин тарихы ераккарак барып тоташа. 1923 елда Токиода булган көчле җир тетрәүдән соң, коммуникацияләрне торгызу максаты куела. Шуннан компаниягә акрынлап нигез салына, телефония өлкәсендә үз эшчәнлеген башлый һәм зур уңышларга ирешә.

Бүген «Fujitsu» электрон компонентлар, аудио- һәм видеотехника җитештерә, программалар белән тәэмин итә. Ул дөнья базарында зур казаныш алган компания. 2010 елда компаниянең 75 еллыгы кысаларында узган «Fujitsu Forum Moscow. Киләчәкне бергә төзибез» исемле конференциядә Россия IT-компанияләре белән хезмәттәшлек, безнең илдә инновацияләрне үстерү проблемалары күтәрелде.

Мәгълүмати технологияләр һәм системалар югары мәктәбе – КФУның иң яшь бүлекләреннән берсе. Биредә гамәли дисциплиналарга басым ясала. Студентлар II курстан башлап төбәкнең иң эре компанияләрендә практика үтә һәм акча эшли, хәтта эшкә урнаша ала. Әлеге мәктәпне тәмамлаган студентларга Казан федераль университеты дипломы бирелә.

Югары мәктәп 6 үзәктән тора. Алар укыту программаларының заман технологияләренә туры килү-килмәвен тикшерә. Студентлар реаль шартларда тәҗрибә туплый, проектларда катнаша, команда белән эшләү нечкәлекләренә өйрәнә.

## • Кайтаваз

# Океан артына сәяхәт

**Алсу НӘГЫЙМОВА,**
Экология һәм география институты студенты

Кичә Экология һәм география институты яшьләр туризмын оештыру һәм студентлар программалары өлкәсендәге иң зур компанияләрнең берсе булган «Star Travel» агентлыгы вәкилләре белән берлектә очрашу уздырды. Океан артында булып кайткан студентлар дөньяның бөек державасы турында юмор да өстәп бер чемодан эмоцияләре белән уртаклашты.

«USA – country of dream and possibilities!» дигән чара дөнья буйлап сәяхәткә кызыксыну уяту, илләрнең көнкүреше, мәдәнияте белән танышуга юнәлтелде. Тормышыбыз шартларын яхшырту идеяләрен уйлау, америка тәҗрибәләрен үзләштерү дә төп максат булып тора.

Институт галимнәре ясаган чыгышларда АКШның дөнья аренасындагы әһәмияте, инвесторлар һәм туристларны үзенә тартып торучы ил булуына басым ясалды. Мондый программада катнашучыларны АКШның табигате, искитмәле тыюлыклары, халыкка хезмәт күрсәтү сокландыра. Мәсәлән, 500 мең кеше яши торган Лас-Вегас шәһәренә бер елга 27 млн. турист килә икән.

Чараны оештыручы географик һәм экологик белем бирү бүлеге мөдиренең тәрбия һәм социаль эшләр буенча урынбасары Рөстәм Фәрхуллин катнашучыларга АКШка бару мөмкинлеге биргән өчен, бүлек мөдире Илгизәр Гайсинга рәхмәт сүзләре җиткерде. Барлык кунакларны да программаларда актив катнашырга, чит телләрне өйрәнергә, Европаның башка илләренә сәяхәткә чакырды.


Эдвард Хәкимов фотосы

● Әшлекле сөйләшү

# Чишелеш җитәкчелеккә бәйле

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

17 ноябрь көнне Татарстан Республикасы югары уку йортлары ректорлары советы каршындагы күпмәдәниятле белем бирүне үстерү буенча вузара координацион советның утырышы булып үтте.

Филология һәм сәнгать институты директоры Рәдиф Җамалетдинов җитәкчелегендә узган утырышта Казан һәм Татарстандагы 23 югары уку йортының уку-укыту эшләре буенча проректорлары, укыту-методик берләшмә җитәкчеләре бүгенге көндә вузларда татар телен укытуның торышы турында фикер алыштылар. Утырышта ТР Министрлар кабинетының ТР халыклары телләрен үстерү бүлеге җитәкчесе Фирая Шәйхиева да бар иде. Ф.Шәйхиева әйтеп үткәнчә, бүгенге көндә телләр турындагы законның яңасын чыгару өстендә эш бара. Законга нигезләнгән программа 2013 елга кадәр төзелгән иде. Хәзер, законга бәйле рәвештә, аның яңасы эшләнә. Төп юнәлешләре түбәндәгеләр булыр дип көтелә: беренчедән, студентлар, югары уку йортын тәмамлаганда, ике телдә дә камил сөйләшергә тиеш. Барыбыз да беләбез: конституциядә татар һәм рус телләре дәүләт телләре буларак билгеләнгән. Утырышта барлык дипломлы белгечләрнең, үзебезнең республикада эшләргә калган очракта, ике телдә аралаша белергә тиешлеге турында сүз барды. Дөрестән дә, кайсы юнәлешне алсак та – медицинамы ул, энергетикамы, авыл хуҗалыгы өлкәсеме – яшь белгеч ике дәүләт телен дә үзләштерергә тиеш. Ф.Шәйхиева ассызыклаганча, мәсәлән, медицина белгечләренә һичьюгы авыруларны тынычландырырдай ягымлы сүзләр әйтә алыр дәрәҗәдә генә булса да. Телне үзләштерүнең ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын студентлар бары тик IV-V курсларда гына төшенә башлый, ләкин инде соң була. Шунлыктан 2012 елда Филология һәм сәнгать институты базасында татар теленә өйрәтү буенча махсус курслар ачарга уйлыйлар. Министрлыкларга килгән хатларның да күпчелеге татар телендә, ә аларны укып аңлар өчен, хезмәткәргә татар телен белү бик кирәк.

Р.Җамалетдинов әйткән фикерләр дә уйландырырлык иде: «Барысы да вуздагы җитәкчелектән тора, әгәр телиләр икән, татар телен факультатив дәресләр буларак та кертергә була», – диде ул. Киңәшмәдә шулай ук татар, рус һәм чит телләргә өйрәткәндә, теориягә генә кайтып калмаска, ә гап-гади аралаша белүдән башларга кирәклеге турында да фикер алыштылар. Әлегә бу мондый типтагы беренче киңәшмә генә булса, декабрь аенда, берникадәр эш эшләнгәч, тагын җыелырга сүз куештылар.

Медицина университеты проректоры Ләйсән Мөхәррәмова исә хәлнең җитәкчелектә генә булмавын, ә профессиональ дәрәҗәдә татар телен укытырга белгечләр җитешмәвен әйтеп узды. Бигрәк тә социаль факультетларда укучы студентларга ике телдә дә иркен сөйләшү зарур, чөнки аларның хезмәтләре кешеләр белән аралашудан гыйбарәт. Ә архитектура-төзелеш университетында, киресенчә, студентларга терминологиянең русча өйрәтелүе отышлырак булу искәртелде. Киңәшмә бик җанлы барды. Бүгенге көндә татар теленең яхшырак үзләштерелүенә җитәкчелекнең беренче адымнар ясавы бик куанычлы хәл, әлбәттә.

Киңәшмә ахырында вуз җитәкчеләренә өй эшләре бирелде: икенче җыелышка, татар теленнән әзерләнгән методик ярдәмлекләрне алып килеп, күргәзмә оештырырга.

Утырышның әһәмияте зур булды. Бердән, вузлар арасында бердәмлек барлыкка килә. Икенчедән, җитәкчелекнең студентларга профессиональ дәрәҗәдә татар телен өйрәтү юлларын эзләве бик зур адым. Киңәшмә барышында, бу мәсьәләнең кайбер вузларда инде чишелгәнлеге, ә кайсыберләрендә әле, гомумән, кузгатылмавы сизелде. Көнүзәгендә торган проблеманың чишелеше, беренче чиратта, әлбәттә, һәр вузның җитәкчелегеннән тора. Ә калганы үзеннән-үзе барачак.

● Бөтендөнья телевидение көне

# Хәрәкәтләнә торган рәсемнәр

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче






Телевидениенең 100 елга якын тарихы бар. Бөтендөнья телевидение көне билгеле бер дата буларак күптән түгел генә бәйрәм ителә башлый. 1996 елның 21 ноябрендә Бөтендөнья телевизион форумы уздырыла һәм 1998 елда БМОның Генераль Ассамблеясе бу көнне Бөтендөнья телевидение көне дип игълан итә. Дәүләтләргә куркынычсызлык, дуслык, икътисади һәм социаль үсеш, мәдәни кыйммәтләргә багышланган телевизион тапшырулар белән уртаклашырга тәкъдим ителә.





Беренче тапкыр сурәтләрне электрон нурлар ярдәмендә билгеле бер ераклыкта тапшыру экспериментлары 1920 еллар башында АКШ, Япония һәм Советлар Союзында башкарыла. Массакүләм таралыш 50нче елларда гына барлыкка килә.

Россия телевидениесе хәрәкәтләнә торган рәсем булган беренче тапшыруны 1932 елда тәкъдим итә. 1937 елда Шаболовкада тәүге телеүзәк ачыла. Тик телевидение үсешенә Бөек Ватан сугышы комачаулый. Сугыш бетәргә бары ике көн кала, телеүзәк үз эшчәнлеген яңадан башлап җибәрә. Европада беренчеләрдән булып даими рәвештә атнага ике тапкыр телетапшырулар чыга башлый.

Кеше күп мәгълүматны зәңгәр экраннар аша ала. Халыкка хәзер сайлау мөмкинлеге зур, җаның теләгән тапшыруны җаның теләгән телеканал аша карый аласың.

*Васил ГАРИФУЛЛИН, журналистика һәм социология факультеты деканы: «Элек төп мәгълүматны басма чаралардан ала идек. Хәзер күбрәк телевидениегә мөрәҗәгать итәбез. Бүгенге көндә татар телевидениесенең аудиториясе шактый киң. Ул бар һәм булачак та! Университет телевидениесенә дә ышанычым зур! Федераль дәрәҗәдәге уку йортында телевидение үзәге булу мәҗбүри. Ул безнең халыкка аң-белем тарата торган канал булырга тиеш».*



### «UNIVER TV»

Казан федераль университетының «UNIVER TV» каналы уку йорты хезмәткәрләрен, студентларны гына түгел, хәтта җөмһүриятебез халкын да вуз яңалыклары белән таныштырып тора. Алар «ITV» телеканалы аша атнасына ике тапкыр дүшәмбе һәм җомга көнне эфирга чыга. Шулай ук язмаларны университет сайтында да карап барырга мөмкин.

Тарих битләрен ачып карасак... «UNIVER TV» каналы әле бик яшь. 1 декабрьдә ул 1 яшьлек Туган көнен бәйрәм итәчәк. Бер ел элек бу көнне тәүге сюжетларын тамашачы игътибарына тәкъдим итәләр. Бернинди база булмаган килеш эшли башлый алар. Коллективның төп составын студентлар тәшкил итә. Уку һәм эшне бергә алып бару җиңел түгел, ләкин хезмәткәрләр зарланмый. Беренчедән, алар тәҗрибә туплый, икенчедән, яхшы хезмәт хакы ала, өченчедән, университет тормышы эчендә кайный. Ниндидер аерым бер юнәлеш буенча гына сюжет эшләү дигән әйбер монда бөтенләй юк, тәҗрибә туплаучы яшь журналист өчен бу тагын бер яхшы мөмкинлек.

Телевидениенең эше гөрләп бара. Алар 471 сюжет әзерләгән. Киләчәккә дә максатлары зурдан. Фәнни якка басым ясап, тапшырулар санын арттырырга телиләр. Бүгенге көндә телевидениегә ихтыяҗ зур. Анда тәүлегенә 24 сәгать эшләргә кирәк. Төшереп кайткан материал иртәгәгә инде искерә. Вакытында эшләмәсәң, тамашачыңны югалттың дигән сүз! «UNIVER TV» каналы хезмәткәрләре актив, өлгер, шуңа күрә алар максатларына ирешә.

### «ЖС»та хәлләр ничек?


Университетыбызның журналистика һәм социология факультетында тележурналистлар 90нчы еллардан бирле әзерләнә. 2003 елда биредә электрон мәгълүматлаштыру чараларының теориясе һәм практикасы кафедрасы ачыла. Әлеге факультет әзерләгән белгечләрнең исемнәре республикабыз халкына гына түгел, хәтта Россия тамашачысына да яхшы таныш. Барыбыз да яратып карый торган «Татарстан – Яңа Гасыр» телевидениесе бөтендөнья татарларын берләштерә. Аның генераль директоры Илшат Әминов, урынбасары Миләүшә Айтуганова, «Яшь ТНВ» бүлеге җитәкчесе Рамилә Сәхабетдинова татар телевидениесен үстерү, алга җибәрү өчен бөтен көчен куя. Флёра Абдуллина, Ләйсирә Фазлыева, Раил Өметбаев, Зөлфәт Зиннуров, Финзия Газизова, Рәмзилә Хөрмәтова кебек танылган журналистлар әзерләгән тапшыру-сюжетлар һәрберебезнең күңелен яулап алды. «Эфир» каналы хезмәткәрләре кыю, туры сүзле булулары белән игътибарны җәлеп итә. Алар арасында Дмитрий Пивоваров, Антон Райхштат, Сергей Шерстнёв, Марсель Нургатин һ.б. шулай ук әлеге факультетны тәмамлаган. Федераль каналларда да безнең якташларыбыз зур уңышлар казана.

Журналистика һәм социология факультеты деканы Васил Гарифуллин билгеләп үткәнчә, алдагы елларда телевидение журналистикасы төркеме II курстан соң гына бүленә торган була. Соңгы ике уку елында исә абитуриентлар беренче курстан ук махсус төркемгә кабул ителәләр. Студентлар университет телевидениесендә практика узалар, курс, диплом эшләрен дә шул темага багышлыйлар.

### Гомумән...

Филология һәм сәнгать институтының татар филологиясе бүлеген тәмамлаган студентлар арасында да танылган тележурналистлар бар. Фәридә Төхвәтуллина, Люция Нотфуллина, Энҗе Шәйхетдинова, Илнар Яркәев, Марсель Әхмәдуллин, Данил һәм Гөлназ Гыйниятовлар безнең кумирларыбызга әйләнде.

Киләчәктә «UNIVER TV» каналы хезмәткәрләре дә зур уңышларга ирешеп, халкыбызга яхшы таныш журналистлар булырлар. Бүгенге көндә алар зур эш башкара – университет телевидениесен төзи. Тамашачы алар хезмәтен дөрес бәяләр дип уйлыйм. Ни генә дисәк тә, алар безнең өчен эшли бит!





Әмир Фазлыйәхмәтов фотолары

• Эшлекле сөйләшү

# Студентлар да БДИ тапшырачак!

Динара ӘХМӘТОВА,
хәбәрче

**Узган атнада университетта зур чара узды. Уку йортыбызның туган көне, ТР Студентлар лигасына 15 яшь тулу, Студентлар бердәмлеге көне уңаеннан, КФУ ректоры Илшат Гафуров, мәгариф һәм фән министры Альберт Гыйльметдинов, Студентлар лигасы президенты Тимур Сөләйманов республиканың иң актив студентлары белән очрашты.**

«Уку йортыбыз зур үзгәрешләр алдында тора. Бу туган көнен аның хәтта яңадан туу дип тә атарга мөмкин. Үзгәрешләр дигәндә, югары сыйфатлы белем алу, яңа проектларны тормышка ашыру күз уңында тотыла. Проблемалар юк түгел, ләкин без аларны хәл итәбез», – диде ректор Илшат Гафуров. Университет җитәкчелеге максатларыңны тормышка ашыру, үзеңне реальләштерү өчен бөтен мөмкинлекләрне тудырырга тырыша. «КФУда төзелә торган инфраструктура коллектив үзәк буларак кулланылачак, ягъни башка уку йорты студентларына шөгыльләнү мөмкинлеге тудырабыз. Физик тәрбиягә зур игътибар бирәбез», – дип өстәде ректор.





Алия Галимуллина фотолары

Очрашу диалог рәвешендә барды. Студентлар кызыксындырган сорауларына җавап алды. Яшь буынны дәүләтнеке булмаган югары уку йортларының киләчәге, андагы белем сыйфаты кызыксындыра. Җитәкчелек фикеренчә, бу өлкәдә хәл ителәсе сораулар җитәрлек. Алар фикеренчә, бездә югары белем бирү XXI гасыр шартларына туры килеп бетми. Хосусый уку йортларына килгәндә, чыгарылыш студентлары белемле, җәмгыять өчен файдалы белгечләр булса, аларга бернинди дә куркыныч янамый.

Республикадагы филиалларның әһәмияте турында да сөйләшү булды. Алар бик күп, ләкин һәр вузның үз эше. Монда министрлыкның катнашы юк. «Тормышта төрле хәлләр була, барсына да әзер торырга кирәк», – диде җитәкче. Студентлар филиалларны ябуның бер зур минусын күрсәтә. Алар фикеренчә, талантлы, актив яшьләр башкалага китә һәм кечкенәрәк шәһәрләр югалту кичерә. Шулай ук Татарстандагы уку йортларының рейтингы булмау турында да сүз кузгатылды. Бу абитуриентларга уку йортын дөрес сайларга ярдәм итәр иде. Түбән Кама шәһәреннән килгән студент Айгөл Аитованың әлеге соравына министр уңай җавап бирде.

Студентлар лигасының социаль эшләр буенча вице-президенты Анна Минеева энергетика һәм техник университетларны берләштерү белән кызыксынды. Әлбәттә, без искелеккә ябышып ятарга, өйрәнгән юл буенча гына йөрергә яратабыз. Яңалыкны тиз генә кабул итәргә дә күнекмәгән. Студент кыз сорау биргәч: «Без сезгә ышанабыз, дөрес нәтиҗәгә килерсез дип уйлыйбыз», – диде. Министр вузларны кушу яклы булуын әйтте. Бүгенге көндә бу идея эшкәртелә икән. «Безнең студентлар вак-вак уку йортларында укыганчы, дөньякүләм танылган, югары дәрәҗәле вузларда белем алырга тиеш. Без нәкъ шундый белем йортлары төзергә телибез», – диде Альберт Гыйльметдинов.

Очрашуда БДИга бәйле сораулар да яңгырады. Алга таба югары уку йорты студентлары да әлеге сынауны үтәчәк. Әлбәттә, бу студентлар өчен яхшы хәбәр түгел. Ләкин белгеч булган кеше бөтен сорауга да, нинди генә шартта булуына карамастан, җавап бирә алырга тиеш. Бигрәк тә мәктәпкә баручы укытучылар өчен бу бик мөһим әйбер. Үзе шуның аша үткән кешегә укучыларына дөрес юл күрсәтү күпкә җиңел булачак. Минемчә, әлеге имтиханның тагын бер уңай ягы бар. Студентның белем дәрәҗәсе дөрес бәяләнәчәк. Укытучы бит «калтырап торган «4»ле» яисә «нык «5»ле» билгесе куярга мөмкин. Монда синең язмышың үз кулыңда, дөресрәге – башыңда. Бөтен нәрсәне дә баллар хәл итә.

Ректорга: «Вуз белән идарә итүдә студентлар катнашырга тиешме?» – дигән сорау бирелгәч, ул: «Студентларсыз уку йорты яши алмый. Алар аның бүгенге торышын да, киләчәген дә хәл итү көченә ия», – диде. Университетта студентлар белән үзара элемтә урнаштыру максатыннан, уку йортының студентлар телевидениесе оешты, «Казан университеты» газетасында «Беседка откровений» сәхифәсе ачылды. Шулай ук фикереңне җиткерү өчен, ректорның электрон мәйданчыгы бар. Сәләтле яшьләрне кайгыртып, вузның үз эчендә грантлар булдыру турында карар да кабул ителде.

Уку йортының эшчәнлеге, планнар, максатлар белән кызыксынып торучы яшьләрнең күп булуын күреп, күңел сөенә. Алар актив, кыю, күпкырлы шәхесләр булып үсә. «Безнең студентларны чит илләрдә бик теләп кабул итәләр. Россиядә югары культуралы, тәрбияле халык яши. Без сезне читкә җибәрүгә каршы түгел, ләкин кире туган илебезгә, туган университетыбызга кайтуыгызны теләр идек», – диде ректор Илшат Гафуров. 207 еллык тарихы булган уку йортыбызда тудырылган мөмкинлекләрне дөрес файдаланыйк.

• Әдәп-әхлак

# Бүләк сайлау - үзе талант

Зилә ФӘСХИЕВА,
хәбәрче

Дустыгызның туган көне. Сез баш ватасыз: нәрсә бүләк итәргә соң? Бергә укый, эшли торган иптәшегез туйга чакырды – яңа өйләнешкәннәргә нинди бүләк алу яхшырак? Яңа ел якынлаша – якыннарыңа нинди дә булса игътибарлылык күрсәтәсе килә. Озакка сузылган командировка яисә ял вакыты бетеп бара – сез сувенирлар, хатыныгызга, улыгызга я кызыгызга вак-төяк бүләкләр эзлисез. Кайчандыр сезне укыткан профессорның юбилее. Аның белән озак еллар күрешкәнегез юк, ләкин укытучыга рәхмәт хисе бервакытта да исегездән чыкмый. Сез аңа нинди яхшылык эшләргә икән, дип уйланасыз.

Бүләк бирү һәрвакыт чын күңелдән булырга тиеш, ул мәхәббәтне, дуслыкны, матур хисләрне белдерә, кешеләрнең берберсенә булган мөнәсәбәтен ачыклагандай була һәм еш кына, төрле матур сүзләргә караганда, күбрәк мәгънә аңлата.

Әгәр сез бүләк сайлаганда ихлас, изге теләктә булсагыз, игътибарыгыз дусларыгызны шатландырачагын белеп, үзегез дә канәгатьләнү кичерәчәксез. Әгәр сез өстегездән бурычны төшерү яки бүтән шундый теләк белән бирәсез икән, ул чагында бүләк сезгә дә аталган кешегә дә бернинди тәэсир итмиячәк. Шуны да әйтергә кирәк: бүләк үзе җанлы әйбер булмаса да, яратып, теләп сайланганмы икәнен һәрвакыт әйтеп тора. Мәсәлән, туган көнгә берәр торт кына алып барсаң, ул үзе турында үзе сөйли: «Мине кунакка килешли юлда гына алдылар, чөнки бу иң җиңел эш. Мине алучылар сезне шатландырырлык һәм истәлек калдырырлык бүләк әзерләү турында алдан исләренә дә китермәделәр».

Бүләк файдалы, кыйммәтле, әллә кирәкле әйбер булырга тиешме? Берсе дә мәҗбүри түгел, тик аның бер «этик» билгесе булсын. Ул сезнең һәм бүләк биреләсе кешенең зәвыгы турында уйлавыгызны күрсәтә Шул ук вакытта бүләкнең файдалы булуы – киң төшенчә. Файдалы булуны без әйбернең гамәли кулланылышы дип кенә аңларга тиеш түгелбез. Перчатка һәм чынаяк та, китап һәм картина да, чәчәкләр һәм ваза да файдалы. Чөнки бу әйберләрнең барысы да, әгәр начар булмаса, үз вазифасын үти. Ләкин шул ук перчатка, кулга сыймаса, файдасызга әйләнә, хуҗага ошамаса, картина шулай ук отышлы вариант түгел. Бүләк бәясе күбрәк кешенең мөмкинлегенә бәйле. Кыйммәтле бүләк бүләк алучыны сезнең алда бурычлы итә.

Бүген теләсә кайсы кибеттә бүләккә ярарлык әйбер табарга мөмкин, ләкин нәкъ менә шушы кеше өчен һәм шушы уңайга бәйле бүләк итәрлек нәрсә бармы соң? Сайлаганда, кардәшлек яисә танышлык дәрәҗәсенә, кешенең яшенә, ни белән кызыксынуына, шөгыленә игътибар итү кирәк.

Бүләкне бирү генә түгел, ала белү дә мөһим бит әле, дуслар. Күпләр кунакның бүләген алып читкә куярга һәм нәрсә бүләк иткәнен кунаклар киткәч кенә карарга ярата. Миңа калса, киресенчә, бүләкне шунда ук карарга һәм аңа үз мөнәсәбәтеңне белдерергә кирәк. Ул сезгә бүләк эзләгән, тырышкан, игътибарсызлык күрсәтеп, ник аның хәтерен калдырырга?

Инә дә бүләк, дөя дә бүләк, дигән мәкальнең асылын аңласак та, кешегә карата ягымлы, җылы мөнәсәбәтнең аның кадәр үк әһәмиятле булуына күпләребез төшенеп бетә алмый. Шуңа күрә, дуслар, үзегезнең игътибарыгызны, ягымлы елмаюыгызны да бүләк эченә «төрергә» онытмаска кирәк!

• Идел киңлекләре

# Туйга килегез...

Сиринә ТРОФИМОВА,
хәбәрче

**Идел буенда гомер итүче удмурт халкы гореф-гадәтләргә, традицияләргә, йолаларга бай. Бүген сезне әлеге милләтнең туй йолалары белән таныштырабыз.**

Кыз сорауның катлаулы ритуалларын узганнан соң, туйга әзерлек чоры башлана. Әгәр дә кыз шул көнне үк булачак иренең йортына китә икән, ул вакытта кияү йортында күңел ачу кичәсе – «ярашон» үткәрелә. Аннан соң кияүгә чыгасы кыз өенә кайтып «сюан» дип аталган кунак ашына әзерләнә башлый.

Җиткән кызлар берничә ел алдан, үзенә күлмәклеккә киндер сугып, миллилекне саклаган бизәлешле (итәкнең аскы өлешенә рәт-рәт итеп 1-2 төрле тасма һәм кулдан бәйләнгән челтәр белән әйләндереп тегәләр) өч-дүрт күлмәк әзерләп куярга тиеш булган. Ул күлмәкләрне «сюан» үтәсе көнне барлык кеше күрерлек итеп киштәгә элеп куйганнар һәм кызның уңганлыгын, булганлыгын шуңа карап та чамалаганнар. Фин-угор төркеменә кергән удмурт халкының (1932 елга кадәр вотяклар булганнар, безнең җирлектә аларны арлар дип тә йөртәләр) традиция буенча күлмәклек материалы күбрәк шакмаклы, куе кызыл, кызыл төстә булган.

Әгәр дә инде кызны сорарга килгән көнне ул әти-әнисе өендә кала икән, башта «сюан», аннан «ярашон» үткәрелә. Бу очракта туй билгеләнгән көнне кияү үз өендә кала, ә әтисе белән олы абыйсы кызны алырга китә. Аларны кыз өендә кабартмалар пешереп каршы алалар. «Сюан»ны үткәрүчеләр арасыннан туй көнне бөтен кеше дә буйсынырлык төп кешене сайлап куялар.

Табын янында утырганнан соң, туй җырлары башлана. Бигрәк тә егет ягыннан килгән кунаклар үзләренең йола җырларын белү осталыгын күрсәтергә тиеш. Аннан соң кызның туган өе белән саубуллашу йоласы башлана. Бирнәне атка яисә машинага чыгарып куйганнан соң, китәсе кыз үзенең бер җиңгәсе белән бирнәле транспортны өч мәртәбә сәгать йөреше уңаенда әйләнергә тиеш. Кияү йортына кайткач та, киленне каршы алучылар аны тагын, кояш әйләнешенә карап, бирнәле йөк тирәли өч мәртәбә әйләндереп чыгара. Ишек алдында ук ботка авыз итәләр. Булачак кайнанасы киленен җитәкләп өйгә алып керә һәм хатын-кызлар өчен әзерләнгән бүлмәдә мендәргә утырта. Туганнары ипи белән май каптыра. Аннан чәчен сүтеп, ике толым итеп үреп, башына уратып куялар. Кайнанасы килененә кызлык чоры бетүен, хәзер инде ир хатыны булуын аңлаткан баш сөлгесен кидертә.

Туй шушы йолаларны башкарганнан соң башланып китә.

● Халәт

# Тәүге күрешү

**Алинә ХӘБИБУЛЛИНА,**
журналистика һәм социология факультеты студенты

БЕРЕНЧЕ ОЧРАШУ... ӘЙЕ, НӘКЪ ТӘ МЕНӘ БЕРЕНЧЕСЕ... НӘРСӘ БЕЛӘН ИСТӘЛЕКЛЕ СОҢ УЛ? ҺӘРБЕРЕБЕЗ ДӘ ХӘТЕРЛИМЕ АНЫ? ӘНӘ ШУЛ СОРАУЛАР БЕЛӘН ЗАМАНДАШЛАРЫМА МӨРӘҖӘГАТЬ ИТТЕМ. Ә АЛАР ИСӘ ҮЗЛӘРЕНЕҢ ЭЧ СЕРЛӘРЕН МИНЕМ БЕЛӘН БҮЛЕШТЕ.


Энҗе Ибраһимова фотосы

***Зилә, 20 яшь:***

– Беренче очрашу минем өчен бик дулкынландыргыч иде. Шундый зарыгып көттем мин Аны. Очрашкач та, Аның күзләренә карарга оялдым. Ул мине кулымнан алу белән, тәнемнән ток үткән сыман булды. Беренче очрашуым кызыл розаларның чын исен тою белән дә истәлекле. Шуңа бу мизгелләр күңелемдә мәңгегә уелып калды.

***Рушан, 24 яшь:***

– Дискотекада очраштык без Альбина белән. Шактый вакыт аркага-арка терәшеп биегән булып чыктык. Шуннан ничектер икебез дә артка борылып карадык. Аны күргәч, мәш килеп биегән җиремнән туктап калган идем мин хәтта. Без биегән көй тукталып, талгыны куелгач, аны биергә чакырдым.

***Айгөл, 20 яшь:***

– Бер егет белән кинода очрашырга сөйләштек. Шул ук көнне мине ошатып йөри торган икенче егет тә нәкъ шул кинога чакырды. Аңа дөресен әйтмәдем, үпкәләтермен дип куркып, кафега бардык. Очрашырга сүз куешкан егетем шалтыраткач, эшем бар иде дип алдарга туры килде.

***Райнур, 25 яшь:***

– Беренче очрашу кинодагыча булмады инде. Житәкләшеп урамда йөрдек, аннан өенә озаттым. Шул.

***Ләйсән, 22 яшь:***

– Егетем булмагач, үземә Казаннан егетләр эзли башладым. Интернет аша танышкан дусларым егермегә җыелды. Ринат исемлесе белән очрашырга сөйләштек. Ул ике сәгатькә бильярд өстәлен арендага алып куйган булган. Ә мин исә бер сәгать ярымга соңга калып килдем. Бильярд уйнарга бары ярты сәгать вакыт калган иде. Беренче күрешү шулай тәмамланды. Ә икенче тапкыр очрашуга барганда, бер сәгатькә соңардым. Егетем сабыр иде, ачуы чыкмады. Бергәләшеп кино карадык.

***Наил, 25 яшь:***

– Кайсын әйтим икән инде? Берсе белән лифтта бикләнеп калган идек. Ачып чыгарганчы, күзгә-күз карашып утырырга туры килде. Шул истә калган.

***Алсу, 33 яшь:***

– Аның белән бер мәктәптә укысак та, игътибар итми идем. Берьюлы: «Алсу, нихәл?» – дип эндәште. Шуннан күзем төште бит. Матур гына киенгән чибәр егет икән. Шул танышудан җиде ел йөрдек. Аннан өйләнештек. Хәзер бер малай, бер кыз үстерәбез.

Әнә шулай дип җавап бирде әңгәмәдәшләрем. Кайберләре күңелендә беренче очрашу мәңгегә уелып калган, ә кайберләренең, үзләре әйтмешли, искитәрлек булмаган. Ә шулай да беренче очрашу тормышыбыздагы якты хатирә булып калырга тиештер. Нәрсә генә дисәң дә, иң беренчесе бит... Бу тормышта бар нәрсә дә тәүге тапкыр була. Тәүге тапкыр булганнар кабатланмас булып хәтердә кала. Беренче очрашу белән дә шундый ук хәлдер, мөгаен.

● Тәнгә – мунча, җанга – юк

# «Тәмәке тарттың мени?»

**Лилия БӘДРЕТДИНОВА,**
хәбәрче

ДӨНЬЯ БУЕНЧА ҺӘР 6 СЕКУНД САЕН ТӘМӘКЕ БЕР КЕШЕ ГОМЕРЕН АЛЫП КИТӘ. БЕР ЕЛГА ҮЛҮЧЕЛӘР САНЫ 5,4 МИЛЛИОНГА ҖИТӘРГӘ МӨМКИН. 2020-2030 ЕЛЛАРГА БУ КҮРСӘТКЕЧ 10 МИЛЛИОНГА ҖИТӘР ДИП КӨТЕЛӘ.

Тәмәке төтене кешелекнең иң зур дошманы булып тора. Һәм иң куркынычы – ул хатын-кызларга һәм балаларга бик тиз начар йогынты ясый.

Статистика күрсәтүенчә, Россиядә елына 332 мең кеше үлә. Икенче Бөтендөнья сугышы 50 мең кешенең гомерен алып китсә, тәмәке тарту ел саен 6 миллионлап кешенең башына җитә һәм яман шеш авырулары белән үлүчеләр санын 30% житкерә. Планетабызда тартучы хатын-кызлар саны 12% житкән. Соңгы елларда Россиянең төрле төнге клубларында тәмәке төтененә буылып «койрык атучы»ларга нәфис затлар һәм яшүсмерләр керә. Яшүсмерләргә килгәндә, шунысын әйтеп үтәргә кирәк: алар инде 10-12 яшьтә тәмәке белән тулысынча дуслашып өлгерә. Беренче тапкыр тәмәке белән дуслашучылар күбрәк 7 яшькәчә балалар... дигән статистиканы читкәрәк куеп, үз башымнан үткәннәрне искә төшерәм.

Балачак дустым Илназ көннәрдән бер көнне мине тәмәке тартырга чакырды. Аңа 7 яшь, миңа – 6. Авыл читендә урнашкан сап-сары бура эченә кереп утырдык та, янәсе, өлкәннәр күрми, и пыскытабыз тәмәкене, и пыскытабыз... Мин, дустым өйрәтүенчә, үпкәдәге һаваны чыгарып бетердем, янып торган тәмәкене иреннәремә китердем һәм, шундый да тәмле әйбер суырган кебек, эчкә суырган идем, күзләрем акайды, авыз куышлыгым гына түгел, үпкәләргә кадәр сасы будыргыч һава белән тулды. Йөткерә-йөткерә, күзләрдән яшьләр атылып чыкты. «Синең әле беренче генә тартуың, шуңа да иялешмәгәнсең, икенчеөченче тапкырында әйбәтләнә инде ул», – ди иптәшем. Тәмәке тарту кыйссасы шуның белән генә бетмәгән икән әле. Икенче көнне минем тәмәке тартканны өйдәге абыем һәм әни белә булып чыкты. Әни матур гына итеп: «Тәмәке тарттың мени?» – ди. Мин: «Юк!» – дим. Әни ирен чите белән генә елмайды да: «Тагын бер авызыңа тәмәке алсаң, шушы авызыңнан кара каннар җибәрәм», – диде. Әнинең тыныч кына, әмма шундый үтемле итеп әйткән сүзләре инде 15 ел колагымда чыңлап тора. Әни әйтмәгән булса да, мин аны кабат тартмас идем, мөгаен!

Тәмәкенең зарары турында язып, кисәтеп, әйтеп килсәләр дә, нишләптер тартучылар кимеми. Шунысы кызганыч: тәнәфес вакытында, югары уку йортында укучы егетләр белән беррәттән, кызларның да чыгып тәмәке тартулары, анда төтенгә буылып басып торганнан соң, кире дәрескә кереп утырып, күңелне болгаткыч исләрен безгә дә суларга мәҗбүр итүләре – җирәнү хисләре уята.

P.S. Ким дигәндә, бер-ике ел тәмәке белән дус таныш кызым ӘНИ булды. Өч көнлек баланың йөрәгенә ясалган сигез сәгатьлек операция – әнисенең хезмәт нәтиҗәседер! Уйланырга сәбәпләр бар, минемчә...

● Йолдызнамә

# Син нинди «яшелчә?»

Хәбәрче **Сиринә ТРОФИМОВА** әзерләде

КАЙБЕР ЙОЛДЫЗСАНАРЛАР КЕШЕЛӘРНЕ, ТУГАН ВАКЫТЛАРЫНА КАРАП, ЯШЕЛЧӘЛӘР БЕЛӘН ТӘҢГӘЛЛӘШТЕРЕРГӘ МӨМКИН, ДИЛӘР. ҮЗЕГЕЗНЕҢ ҺӘМ ТАНЫШЛАРЫГЫЗНЫҢ НИНДИ ЯШЕЛЧӘ ИКӘНЕН УКЫП КАРАГЫЗ ӘЛЕ, БӘЛКИ, ЧЫННАН ДА ДӨРЕСТЕР.



***Чөгендер*** (гыйнвар) – дөрес тукланса, дөрес тормыш рәвеше алып барса, озын гомерле һәм сәламәт булыр. Тыныч холыклы, тавышланып, гауга чыгарып йөрергә, бәхәсләргә керергә яратмый. Оптимист, нинди генә хәлдә калса да, рухи күтәренкелеген югалтмый. Тирә-юньдәгеләргә тәэсир итү көченә ия.




***Кәбестә*** (февраль) – аралашучан, киң күңелле, эчкерсез, кунакчыл кеше. Тышкы гадилеге астына катлаулылык, күпкырлылык яшеренгән. Башкаларга сиздерми генә бер халәттән икенче халәткә күчә белә. Кыенлыклардан курыкмый. Алар аны киресенчә чыныктыра гына. Төрле шартларга яраклашу сәләтенә ия.



***Кишер*** (март) – матур, нәфис, нәзәкатьле. Әмма балачакта дөрес булмаган тәрбия алса, бу сыйфатлар капма-каршыга әйләнергә мөмкин. Еш кына тышкы кыяфәте эчке дөньясы белән тәңгәл килми. Астыртын, салкын, үз эченә бикләнгән. Аның чын йөзен бик сирәкләр генә белә.



***Бәрәңге*** (апрель) – күзгә ташлана торган матур түгел, әмма искиткеч сөйкемле. Теләсә нинди компаниядә үз кеше була ала. Ышанычлы, кыю, кайчагында артык тиз кызып китүчән. Хатын-кыз «бәрәңгеләр» хәрбиләрне бик яраталар. Оештыру эшләрендә, җитәкче урыннарда уңышка ирешәләр. Хыялыйлар.



***Патиссон*** (май) – чибәр, төгәл, кайчагында кыланчырак зат. Холкы каршылыклы һәм ярсу. Игътибар үзәгендә булырга ярата. Әгәр дә шулай булмый икән, моны бик авыр кичерә. Акыл хезмәтен физик хезмәттән өстенрәк куя. Романтик, кирәгеннән артык хыялый кеше.



***Төче торма*** (июнь) – тыныч, сабыр кеше. Әмма шунысы бар: тынычлыгы астында аның әллә нинди куркыныч сыйфатлары яшеренеп ятарга мөмкин. Яхшылык кылырга да, шундый ук җиңеллек белән явызлык кылырга да сәләтле кеше. Бик еш икеләнеп кала, сайлый, карар кабул итә алмый интегә.



***Ташкабак*** (июль) – зифа, озын буйлы, батыр кыяфәтле. Аралашканда, бераз дорфарак булырга мөмкин. Әмма бу беренче карашка гына шулай. Асылда ул артык хисчән. Кайбер очракларда оятсыз кешегә әйләнергә мөмкин. Уңышсызлыкларны бик авыр кичерә, төшенкелеккә җиңел бирелә. Дуслыкка һәм мәхәббәткә тугрылыклы. Башлаган эшен ахырына кадәр башкарып чыгарга тырыша.



***Помидор*** (август) – тормышка гашыйк, сөйкемле, мөлаем һәм тәмлетамак. Игътибар үзәгендә булырга, күзне чагылдырырлык итеп киенергә ярата. Кыен, четерекле хәлләрдә бик еш югалып кала. Аралашу булмаганда, тормыштан тәм тапмый башлый, «тоныклана». Тормышта гомер буена кемнеңдер әйдәп, «җитәкләп» баруына мохтаҗ.



***Шалкан*** (сентябрь) – яшерен тормыш белән яши. Үз эченә йомылган, шактый эчкерле. Әмма беренче карашка салкын, сөйкемсез генә тоелса да, аны яхшы белүчеләр күңеленең ни дәрәҗәдә матур икәнен сизми калмыйлар. Чын дуслары өчен аңардан да ышанычлы кеше юк.



***Кыяр*** (октябрь) – горур, үзсүзле, артык кыенлыклар күрми генә, һәрвакыт максатына ирешә. Бик серле зат. Теләсә кемне үзенә карата ала. Һәр компаниянең үзәгенә әверелү сәләте бар. Хыялый, гүзәллеккә табына. Комфорт һәм җан тынычлыгы ярата. Яхшы психолог. Еш кына башкаларның йомшак якларын шәхси максатларда куллана.



***Суган*** (ноябрь) – кызып китүчән, ләкин гадел кеше. Аның дәлилләре кискен, әмма һәрвакытта да ышандыргыч була. Киенергә-ясанырга, үз-үзен күрсәтергә ярата. Кыйммәтле ташлар, матур әйберләр белән мавыга. Хисчән, тәвәккәл, очраклы гамәлләр кылырга мөмкин. Шулай булса да, күбрәк акыл белән эш итә. Кискенлеге кешеләрне этәрми, киресенчә, тарта, җәлеп итә. Һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер.



***Кабак*** (декабрь) – көйсез, авыр аралашучан, аның җаена тору кыен. Барысы да үз-үзенә ышанмаганлыктан. Башкалардан бәйсез, мөстәкыйль булып кыланса да, дусларының ярдәменә мохтаҗ. Үзе, ярдәм итә алса да, алмаса да, һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер. Бик үзсүзле, әмма гаҗәеп игелекле зат.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ

Тираж 999

Мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, Л.Н.Бәдретдинова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты

Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Сул Болак ур., 44 й., 6 Б каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: (843) 292-22-91, 89053711571.

Электрон почта: tggpu-tat@yandex.ru. Сайт: ksu.ru

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.

Газета бушлай таратыла